**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«30» июль 2024 ел** **№ 102**

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 14.11.2017 елгы 71 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пункты, шулай ук «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 36 статьясы нигезендә карар ителә:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"- су белән тәэмин итү һәм су агызу объектлары, мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, аллеялар, яшел утыртмалар, һәйкәлләр, бәйрәм чаралары уздыру урыннары, спорт объектлары һәм гомуми файдаланудагы башка объектлар биләгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата җирле үзидарә органнары, бюджет, казна учреждениеләре.».

2. Әлеге карарның 3 статьясындагы 5 абзацы үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Кече Салтык
авыл җирлеге Советы Рәисе А.Г. Җиһаншин